# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

Әлеге Закон "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирә.

1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.6, 2.7, 3.2 – 3.7, 4.2, 4.4, 5.1, 5.2, 5.3 – 5.6 статьяларында (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль пассажир йөртүләргә карата), шулай ук 6.1 – 6.3 статьяларында (җирле бюджет акчалары өлешендә) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү буенча

Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

**2 статья. Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган срок**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән срокка бирелә.

**3 статья. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән башкарыла.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләү, әлеге Закон кушымтасына таянып, Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативлар исәпләү методикасы нигезендә башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

**4 статья. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү зарурлыгы булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырылалар.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органына җирле үзидарә органнарының тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгать нигезендә

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**5 статья. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди һәм финанс чараларыннан өстәмә рәвештә файдаланырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

2. Җирле үзидарә органнары үзләренә әлеге Закон белән бирелгән дәүләт вәкаләтләрен законда билгеләнгән тәртиптә үтәргә тиеш.

3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документларны һәм мәгълүматны вәкаләтле дәүләт органнарына бирергә тиеш.

4. Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тикшереп торуны гамәлгә ашыруда кирәкле ярдәм күрсәтергә тиеш.

**6 статья. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җирле үзидарә органнарыннан һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча документлар һәм мәгълүмат соратып алырга;

2) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә тикшерүләр үткәрергә;

3) җирле үзидарә органнарының яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ачыкланган закон бозуларны бетерү турында язма күрсәтмәләр бирергә.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди һәм финанс чараларын тапшырырга;

2) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны, шулай ук әлеге максатларга бирелгән матди һәм финанс чараларыннан файдалануны тикшереп торырга;

3) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча оештыру-методик ярдәм күрсәтергә.

7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисаплылык тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапларны җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органына хисап кварталыннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәвештә бирәләр.

8 статья. **Җирле үзидарә органнарының аларга тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тикшереп тоту**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органы – җирле үзидарә органнарының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен түбәндәге юллар белән тиешенчә гамәлгә ашыруы өлкәсендә:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) күрсәтелгән орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә күчмә тикшерүләр, шулай ук кирәк булган саен планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан түбәндәге юллар белән максатчан файдалану өлешендә:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча кирәк булган саен, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнарны бозуның ачыкланган фактларына бәйле күчмә тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

3) җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен түләүсез файдалануга тапшырган очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтен түбәндәге юллар белән саклау һәм аннан тиешенчә файдалану өлешендә:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча кирәк булган саен, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнарны бозуның ачыкланган фактларына бәйле тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү.

9 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракларда туктатыла:

1) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнары тарафыннан закон таләпләрен үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәү;

3) федераль законнарны яисә Татарстан Республикасы законнарын нәтиҗәдә җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкин булмаслык итеп үзгәртү.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс һәм матди чараларны кире кайтаруга китерә.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнардагы таләпләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органы күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органнарына кергән көненнән алып 10 көннән дә соңга калмыйча һичшиксез каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органына язма рәвештә кичекмәстән хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органы җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны

туктату турында тәкъдим һәм Татарстан Республикасының тиешле закон проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертә.

10 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әгәр чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү каралган булса, әлеге Закон нигезләмәләре күрсәтелгән закон белән ел саен гамәлгә кертелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары, әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә шушы Законга туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 30 июле
№ 60-ТРЗ

"Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта

**Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативлар исәпләү методикасы**

1. Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнде.

Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең (алга таба – субвенцияләр) күләмен исәпләү тәртибен билгеләүгә юнәлдерелде.

2. Субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$Si = k \times Li$,

монда:

Si – i-муниципаль берәмлеге өчен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләме;

Li – i-муниципаль берәмлегендә ел дәвамында дәүләт вәкаләтләренең үтәлешен тәэмин итү өчен кирәкле агымдагы чыгымнар нормативы (алга таба – агымдагы чыгымнар нормативы);

К – муниципаль берәмлектә яшәүчеләр саны.

Агымдагы чыгымнар нормативы елга бер кешегә 30,0 сумны тәшкил итә.